| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>САХАРОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>САХАР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.06.2021 № 15

с.Сахаровка

**Сахар авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Сахар авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Сахар авыл җирлеге Советының 2016 елның 4 апрелендәге 28 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 12.1 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 251-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 24 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 2 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахар авыл җирлеге Уставы нигезендә,

**Сахар авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Сахар авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Сахар авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Сахар авыл җирлеге Советының 2016 елның 4 апрелендәге 28 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:

«21. Сахах авыл җирлеге Советы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы зат депутат итеп сайланганнан соң дүрт ай эчендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирә, аңа вакантлы депутат мандатын тапшыру яки аның вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыруы туктатылган көннән соң, шулай ук мәгълүмат тапшыру елына (хисап чоры) килгән һәр ел өчен, хисап чорында килешүләр кылган очракта, керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 маддәсендәге 1 өлешендә каралган. Хисап чорында мондый алыш-бирешләр башкарылмаган очракта, күрсәтелгән зат бу хакта Татарстан Республикасы Президентына, әлеге Нигезләмәнең кушымтасы нигезендә махсуслаштырылган мәгълүмат ресурсыннан файдаланып, керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү өчен хәбәрнамә җибәрү юлы белән хәбәр итә (dohod.tatar.ru).

Әлеге пункт белән каралган уведомление, шулай ук белешмәләр (хисап чоры дәвамында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 маддәсендәге 1 өлешендә каралган алыш-бирешләр башкарылган очракта) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокта бирелә.»;

2) түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

«Сахар авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Сахар авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Сахар авыл җирлеге Советының 2016 елның 4 апрелендәге 28 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә Кушымта

**Татарстан Республикасы Президентына**

______________________________

**Хәбәрнамә**

Мин, Алексеевск муниципаль районының Сахар авыл җирлеге Советы депутаты ____________________________________________________________,

*фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта)*

«___»____________ _______ туган елы, паспорт сериясе ______№_____________

____________________________________________________________________,

*паспортын биргән орган һәм бирү датасы*

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $12^1$ маддәсендәге 4.2 өлеше һәм «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 маддәсендәге 4.1 өлеше нигезендә Сезне, мин, минем хатыным (ирем) һәм (яисә) балигъ булмаган балаларым тарафыннан «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012

елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 маддәсендәге 1 өлешендә каралган килешүләр (җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар), санлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча килешүләр, гомуми суммасы безнең (минем) һәм хатынымның (иремнең) гомуми суммасыннан соңгы өч елдагы хисап чорына кадәрге кеременнән артып киткән акчалар), хисап чоры дәвамында 20___ елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр башкарылмаганлыгы турында хәбәр итәм.

Әлеге белешмәләрнең дөреслеген раслыйм.

«___»___________ 20____е.

_____________________________________________

*хәбәрнамә тапшырган затның имзасы*

_____________________________________________________________________________

*(хәбәрнамә кабул итүгә вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта) һәм имзасы)*».

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (https://alekseevskiy.tatarstan.ru/), Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Сахар авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Л.В.Шаброва**